ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август, 2024 ел № 35/16

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 20 ноябрендәге 27/18 номерлы Карарының көчен югалтуын тану хакында

«Табигать дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 20 ноябрендәге 27/18 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2007 елның 7 декабрендәге 233-235 саннарында басылган;

2) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 18 июнендәге 41/16 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2009 елның 3 июлендәге 124-126 саннарында басылган,

3) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының 2007 елның 20 ноябрендәге 27/18

номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 17 июнендәге 40/09 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2015 елның 24 июнендәге 45 санында басылган;

4) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 27 маендагы 7/7 номерлы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 28.05.2021 урнаштырылган.

2. Әлеге Карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев